# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Илбәк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**14 ноябрь 2020 ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 14 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының протоколы төзелде:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 150 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (ике телдә урам исемнәре язылган күрсәткечләр һәм торак йортлар өчен номерлар әзерләү/сатып алу, триммер һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу);
- Илбәк авылы җирлегенең урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, алмаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Җиңү көне», «Сабантуй», «Өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр һәм сувенир продукциясе сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү өчен килешү буенча хезмәт күрсәтү;
- Илбәк авылындагы юлларны кардан чистарту (килешү буенча түләү).

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 161 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 105.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен – 104, «КАРШЫ» позициясе өчен 1гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, **гражданнар җыены карар итте**:

1. Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге

уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 150 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (ике телдә урам исемнәре язылган күрсәткечләр һәм торак йортлар өчен номерлар әзерләү/сатып алу, триммер һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу);
- Илбәк авылы җирлегенең урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, алмаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Җиңү көне», «Сабантуй», «Өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр һәм сувенир продукциясе сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү өчен килешү буенча хезмәт күрсәтү;
- Илбәк авылындагы юлларны кардан чистарту (килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Илбәк авылы, Ә.Вәлиев ур., 10а йорт; Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендынларында урнаштырырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Әсәдуллина